Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл Советы

КАРАРЫ

12 декабрь 2024 ел №97

Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл Советының 2018 елның “24” августындагы 57 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы «Татарстан Республикасында депутатларның, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә

Колшәрип авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл Советының 2018 елның “24” августындагы 57 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл Советының 2018 елның 10 декабрендәге 60 номерлы, 2020 елның 18 декабрендәге 10 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 46 номерлы 2022 елның 14 декабрендәге 52 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 89 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад (11 группа хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 20 985 |

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары | 20 566» |

1.2. карарга 2 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи затларының ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Ай саен акчалата бүләкләү күләме (11 группа хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башлык | 20 991 |
| Башлык урынбасары | 15 085» |

2. Әлеге карарны Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 январеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Колшәрип авыл
җирлеге башлыгы — А.Ф. Кәшәфетдинов